Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-2**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 19 декабрендәге VI-3 номерлы карары белән расланган 2020 – 2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планына (Программасына) үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру максатларында, "Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 24 июлендәге XX-20 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру турындагы Нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. "2020-2021 елларда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль мөлкәт объекты исемлеге һәм сыйфатламасы" дигән 2 Бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итеп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 19 декабрендәге VI-3 номерлы карары белән расланган 2020 – 2021 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планына (Программасына) үзгәрешләр кертергә:

| № п/п | Аталышы | Урнашу урынының адресы | Саны (данә) | Функциональ билгеләнеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | FIAT DUCATO автобусы, чыккан елы 2009, таныклау номеры (VIN) - Z7G244000AS012611, ак төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | В классы М2 категориясе, балаларны йөртү өчен махсус | Иректе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 2 | FIAT DOBLO 223 AXP1A автомобиле, чыккан елы 2010, таныклау номеры (VIN) - XU3223000BZ306744, ак төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | | Ирекле |
| 3 | TOYOTA LAND CRUISER 150 автомобиле, чыккан елы 2010 таныклау номеры (VIN) - JTEBU3FJ805007243, көмеш төсендә | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | | Ирекле |
| 4 | FORD EXPLORER, автомобиле, чыккан елы 2015 , таныклау номеры (VIN) – Z6FBXXESWBFD30422, ак төстә. | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп. | 1 данә | | Ирекле |
| 5 | 1 катлы агач бина, кадастр номеры 16:34:040102:286 | Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Биектау ав., Р.Хакимов ур., 1 й. | | | Ирекле |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

И.Р. Таҗетдинов